**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**СОВЕТЫ**

# КАРАР

№ 44 12.03.2021ел.

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районында муниципаль хезмәт турында яңа редакциядәге Нигезләмә хакында» 24.08.2018, № 158 карарына үзгәрешләр кертү турында

«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законына һәм Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 26 декабрендәге 96-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1.Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районында муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә (Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районында муниципаль хезмәт турында яңа редакциядәге Нигезләмә хакында» 2018 елның 24 августында 158 номерлы карары белән расланган) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1). 30 бүлегендәге 30.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«30.2. Муниципаль хезмәт стажын раслаучы төп документ булып билгеләнгән үрнәктәге хезмәт кенәгәсе һәм (яисә) законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләр тора.».

2) 30 бүлегендәге 30.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«30.4. Хәрби хезмәт, аңа тиңләштерелгән башка хезмәт чоры, шулай ук Федераль Салым полициясе органнары, таможня органнары хезмәткәрләренең хезмәт итү чоры хәрби билетлар, хәрби комиссариатлар, хәрби бүлекчәләр, архив учреждениеләре белешмәләре, хезмәт исемлекләре, законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән, хезмәт кенәгәсендәге язмалар һәм (яисә) хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләр белән расланырга мөмкин.».

3) 34 бүлегендәге 4 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт кенәгәләрен алып бару (булган очракта), муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан муниципаль хезмәт узган чорда хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүматлар формалаштыру һәм әлеге мәгълүматларны

мәҗбүри пенсия иминияте системасында индивидуаль (персонифицияләнгән) исәпкә алу турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә, Россия Федерациясе Пенсия фондының мәгълүмат ресурсларында саклау өчен тапшыру;».

2) 34.1 бүлегендәге 11 пунктының 4 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләр һәм (яки) хезмәт кенәгәсенең күчермәсе;».

2. Әлеге карарны Аксубай муниципаль районы сайтында интернет челтәрендә (http://aksubayevo.tatarstan.ru) урнаштырырга һәм_хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Аксубай муниципаль районы Советының Җирле үзидарә, законлылык, хокук тәртибе, регламент һәм депутат этикасы буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Аксубай муниципаль районы башлыгы,

Совет Рәисе К.К.Гилманов